# КАРАР

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлеге составына керүче Иске Пәлчекәү торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**11.11.2022** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 11 нче ноябрендә булып узган гражданнар җыены нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге сорау буенча беркетмә төзелде:« Яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлегенең Иске Пәлчекәү торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндез белем алучы студентлардан, I төркем инвалидлар, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнардан,Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан кала, 2023 елда үзара салымны 500 (биш йөз) сум күләмендә кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотарга-- зираттагы агачларны кисү.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 36 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 27 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен 24 җыенда катнашучы тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен 3 җыенда катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлегенең Иске Пәлчекәү торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип санарга.

2. Яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлегенең Иске Пәлчекәү торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндез белем алучы студентлардан, I төркем инвалидлар, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнардан,Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан кала, 2023 елда үзара салымны 500 (биш йөз) сум күләмендә кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотарга:

-- зираттагы агачларны кисүсоравы буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре»бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлегекарарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Югары Шепкә
авыл җирлеге башлыгы — Камалиева Л.М.